ТЕРӘК КӨЧЕ
Алабугада туган телне саклау һәм үстерү мәсьәләләре турында сөйләштеләр

> 2

ВАКЫТЫ ОЗАЙТЫЛА
Бакчачыларга тагын бәхет елмаерга тора

> 2



АВЫЛ ХӘЛЛӘРЕ
Сала кешесе алдан аяк киенергә ярата

> 3

БЕРГӘ ЖЫЕЛГАНДА
Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 58 (28831) | Шимбә | 23 апрель | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

БАЛАЛАРГА АКЧА ЖӘЛ ТҮГЕЛ

Җәйге ял

Әти-әниләр балаларның ялы хакында яздан ук уйлый башлый. Бүгенгә лагерьларга ун мең юллама сатылган инде. Быел җәй 182 меңнән артык бала шәһәр чите, чатырлы, мәктәп яны лагерьларында, Кара диңгез яры буенда ял итә алачак. Бу – барлык балаларның 48 проценты дигән сүз.

«ВТ» архивыннан

«Безнең бурыч – балаларның ялын имин һәм сыйфатлы итү», – диде Татарстан яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов Министрлар Кабинетында балалар ялына багышланган ведомствоара комиссия утырышында. Аның әйтүенчә, хәзерге вакытта балаларны кабул итәчәк ял итү үзәкләренең исемлеге барлана. Апрель аена исемлеккә 1268 оешма кертелгән. Җәйге ял өчен 1,7 миллиард сум акча бүлеп бирелгән. Бу узган елгыдан 88,28 миллион сумга күбрәк. 42 меңнән артык юллама республика хисабыннан бушлай биреләчәк, шуның 12 меңгә якыны – тормышта авыр хәлдә калган үсмерләр өчен. 5 мең үсмер Кара диңгез яры буйларында, «Артек», «Орленок» бөтенроссия балалар үзәкләрендә күңел ачарга җыена.

Бер караганда, өйдә дә ял итеп була. Замана ата-анасы лагерьга балаларының сәләтен ачар өчен җибәрә. Аларны бигрәк тә профильле сменалар кызыксындыра. Узган елгы ял файдасыз узмаган. Ата-аналар лагерьга барган балаларның 26,1 проценты – иҗади, 21 проценты – спорт ягыннан ачылуын, 15,7 проценты иркенрәк аралаша башлавын әйткән. Ялны оештыручылар быел да сменалар кызыклы, файдалы булыр дип вәгъдә итә. Быел март аенда «Җәй» республика үзәге әти-әниләр һәм балалардан ял турында сораштыру уздырган. «Бигрәк тә нәрсә истә калды?» дигән сорауга, ял итүчеләрнең 25,2 проценты – яңа дуслар белән танышу, 16,1 проценты – конкурсларда, ярышларда җиңү, 12,6 проценты сәхнәдә уңышлы чыгыш ясау, дип җавап биргән.

– Балалар өчен лагерь – яңа дуслар табу, аралашу һәм үз-үзеңне күрсәтү мөмкинлеге. Без, үз чиратыбызда, лагерьның кыйммәтен яхшы аңлыйбыз. Ялны оештыручылар, сездән кешбэк программасына гаиләләргә мөһим ярдәм итеп каравыгызны сорыйм. Икенче ел рәттән лагерьларга сатып алынган юлламаның ярты бәясен кире кайтарып була. Бу мөмкинлекне 31 марттан 31 августка кадәр кулланырга мөмкин. Быел шәһәр чите генә түгел, чатырлы лагерьлар да кешбэклар кайтара ала, – дип аңлатты Тимур Сөләйманов.

«Болгар» радиосы мөхәррире Люция Шәрәфиева да бу мөмкинлектән файдаланган.

– Әмирханның лагерьга беренче генә баруы түгел. Быел тагын «Сәләт»не сайлаган. 14 көнгә юллама бәясе – 27 мең сум тирәсе. Ике көн эчендә түләнгән акчаның яртысы кире кайтты. Болай иткәндә, хәтта ике сменага җибәреп була. Бик уңайлы. Танышларым юлламаларның 15 минут эчендә сатылып бетүеннән зарланышып та алды әле, – диде Люция Шәрәфиева.

Кешбэк программасы турында белмәүче әти-әниләр дә шактый булып чыкты. Нинди нәрсә ул, дип гаҗәпләнүчеләр дә булды.

«Беренче тапкыр ишетәм. Безнең балалар өйдә ял итә, мәктәп яны лагерена гына баралар», – диде Сабадан ике бала әтисе Марат Әхмәтвәлиев. Шулай ук Казанда яшәүче Альбина Киселеваның да бу хакта ишеткәне юк икән. «Ике балабыз бар. Берсенә – 7, икенчесенә – 9 яшь. Безнең ял өч ай буе әби-бабайда үтә. Әтисе, кечкенә әле алар дип, лагерьга җибәрүгә каршы. Мин үзем риза. Яхшы хәбәр әйттегез, кешбэк программасы турында уйлап карыйсы булыр әле. Җәй буе авылда ятмаслар бит», – ди Альбина.

Иминлек, инфраструктура, кадрлар, кызыклы программа. Ялны оештыручылар менә шуларга игътибар бирергә тиеш. Иминлек мәсьәләсенә килгәндә, каравылчыларга таләпләрне арттырачаклар. Моның өчен өстәмә 30 миллион сум акча бүлеп бирелгән. Министр әйтүенчә, лагерьларда сак хезмәте эшчәнлегенә контрольне көчәйтергә кирәк. Сак предприятиеләреннән пенсия яшендәге кешеләрне җибәрү очраклары бар. Һөнәри белемгә таләпләрне арттыру мөһим.

Коллегиядә туклану, азык-төлек сатып алу темасы да күтәрелде. Мисал өчен, хәзер оешма продукцияне ведомствоара комиссия белән килештерелгән бердәнбер товар китерүчедән сатып алырга тиеш. Шулай ук Тимур Сөләйманов, урманнарда урнашкан лагерьларның иминлеген көчәйтү өчен, Урман кодексына үзгәрешләр кертергә тәкъдим итте. Бу очракта аларны койма белән әйләндереп алу мөмкин булачак. Хәзерге вакытта бу рөхсәт ителми. Сүз уңаеннан, күп кенә лагерьлар урман фондында урнашкан. Әйтик, 94енең 33е капиталь ремонт программасына эләккән. Ремонт дигәндә, «Балаларга – ял» яңарту программасы нигезендә быел 22 лагерь төзекләндереләчәк, 2019–2021 елларда 26сына ремонт ясалган. Кырымда республика балалары өчен яңа лагерь ачарга җыеналар.

Коронавирус инфекциясенә бәйле чикләүләр киметелә. Роспотребнадзорның республика идарәсе башлыгы урынбасары Любовь Авдонина әйтүенчә, аниматорларны да чакырырга була, тик чараларны ачык һавада үткәрергә кирәк. Лагерьларга балаларны кабул итү саны чикләнми. Идарә белгечләре туклану буенча мәгариф оешмаларында семинарлар үткәрәчәк. Узган ел барлык кагыйдә бозу очракларының 26 проценты туклануга туры килгән. Балаларның һәм үсмерләрнең җәйге ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия рәисе, Премьер-министр урынбасары Ләйлә Фазлыева, барлык таләпләрне үтәп, балаларның ялын файдалы һәм күңелле итеп уздырырга чакырды.

ЯКТЫ БӘЙРӘМ

Пасха бәйрәме уңаеннан Татарстан Республикасы Президенты РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ КОТЛАВЫ

Православие динендәге хөрмәтле ватандашлар!

Сезне Бөек пост тәмамлану һәм Христосның яңадан туу бәйрәме уңаеннан чын йөрәктән тәбрик итәм.

Бөтен дөнья христианнары өчен Пасха – аеруча тантаналы күтәренкелек вакыты, аларның һәрберсенең тормышында һәм тулаем кешелек тарихында гаять зур вакыйга. Христосның яңадан тууы мәңгелеккә әверелгән, гөнаһлардан арындырылган яңа тормыш башлану турында могҗизалы хәбәр билгесе буларак кабул ителә. Пасха кешеләргә өмет, явыз көчләр алдында куркып, каушап калмаска көч бирә, камиллек үрләренә юл ача.

Без яшәгән четерекле заманда уртак җиребездә барлык милләт һәм дин вәкилләре тарафыннан тупланган мәңгелек рухи хәзинәләрне – төрле халыкларның диненә, мәдәниятенә һәм теленә ихтирамлы мөнәсәбәтне, үзара аңлашуны саклау һәм көчәйтү бигрәк тә зур әһәмият ала. Бөек язучы Николай Васильевич Гоголь бу бәйрәмнең асылы әлеге тантаналы көндә кешене олылауда, аны иң-иң газизеңдәй кочагыңа алуда, иң кадерле туганың итеп күкрәгеңә кысуда, очратканда, иң якын дустыңны күргәндәй сөенүдә чагыла дип аңлата.

Пасха ул – тынычлыкка, рухи яңарышка, миһербанлылыкка, тәүбә итүгә, үпкә-ачу сакламаска Илаһтан иңдерелгән өндәү. Православие, ислам һәм башка традицион диннәр арасында элек-электән нык дуслык-татулык урнашкан Татарстанда Христосның яңадан тууын бәйрәм итү һәрчак кешеләрнең бер-беренә хәерхаһлылыгы һәм бердәмлеге рухында уза. Православие динендәге ватандашлар гаилә-җәмәгатьләре, кардәшләре, күршеләре һәм хәзерге көндә аеруча ярдәмгә мохтаҗ, йорт-җирләрен ташлап, күченеп килергә мәҗбүр булган кешеләр белән үз йөрәк җылысын һәм бүләк-күчтәнәчләрен бик теләп бүлешер дип ышанам.

Нурлы Пасха бәйрәме дин тотучыларны иң мөкатдәс хакыйкатькә, хөрлеккә һәм әхлакый камиллеккә ирешү ниятләрендә ныгытсын! Сезгә бәхет, сүрелмәс яшәү дәрте, сәламәтлек һәм иминлек телим!

Дару бәясе төшә

Россиядә дару бәяләре әкренләп төшә. Аерым алганда, левомеколь – 1,5, ренгалин 1,4 процентка арзанайган. Росстат 9–15 апрель чорына шундый мәгълүматлар китергән. Моннан тыш поливитаминнар (1,3 процентка), эргоферон (1,2%), валидол (1,1%), корвалол (0,9%), аллохол (0,7%), анальгин (0,4%) хакы кимегән.

Шулай ук смартфон (2,7 процентка), телевизор (2,1%), тузан суырткыч (2%) бәяләре төшкән. Әйтергә кирәк, 2–8 апрель чорында бу товарлар инде 5–9 процент чамасы арзанайган булган. Ә менә беренче чиратта кирәкле кайбер сәнәгать товарлары, киресенчә, кыйммәтләнгән. Мәсәлән, исле сабын – 2,4 процентка, теш пастасы – 1,9%, кер порошогы – 1,3%, йорт хайваннары өчен коры ризыклар – 2,2 процентка. Кайбер төбәкләрдә шәһәр җәмәгать транспортында йөрү бәяләре арткан (0,4–1,3 процентка).

Балык тоту тыела

Уылдык чәчү чоры җитү сәбәпле, 25 апрельдән Татарстанда «Уылдык чәчү-2022» кисәтү эшләре башлана. Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Рамил Шәрәфетдинов су биоресурсларын саклау мәсьәләләре буенча республика советы утырышында шулай дип белдергән. Аның әйтүенчә, республикада 5 июньгә кадәр сәнәгать колачында, ягъни күпләп балык тоту тыела. Балыкчылык кагыйдәләрен бозган өчен административ, шулай ук җинаять җаваплылыгы каралган.

Һәвәскәр балыкчыларга килгәндә, аларга яр буеннан балык тоту рөхсәт ителә. Ләкин күп дигәндә ике кармак һәм бер калкавыч белән генә! Балык тоту, су җәнлекләрен аулау өчен барлык төрдәге ятьмә, тозаклар, утлы һәм пневматик корал, капкыннар һ.б. куллану тыела. Шул ук вакытта аларны куып, миңгерәтеп, яктылык белән куркытып тотарга ярамый. Моннан тыш вак балыкларны (әйтик, озынлыгы 40 сантиметрдан артмаган судакны, 25 сантиметрдан кечерәк корбан балыгын, 32 сантиметрдан кечерәк чуртанны) тоту һәм эшкәртү тыела. Балык тотуның тәүлеклек нормасы да бар. Мисалга, корбан балыгы, судак, чуртан, сазан – 5 килограммнан, кысла 20 данәдән артмаска тиеш.

Белеп тор!

Тамак өчен түгел, күңел хакына

Быел республикакүләм ифтар мәҗлесе 30 апрельдә «Казань Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәгендә узачак. Чара турында матбугат очрашуында сөйләделәр. X республика ифтар ашы Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүенең 1100 еллыгына багышланачак.

«Ифтар ашы Татарстанның бөтен почмакларыннан 10 мең кешене җыяр дип ниятлибез. Алар арасында төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр, чит төбәкләрдән кунаклар, мохтаҗлар һәм аз керемлеләр, рәсми затлар да бар», – дип сөйләде Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов. Ул шулай ук рамазан аеның ахыргы ун көненә аеруча игътибарлы булырга, гыйбадәтләрне арттырырга өндәде.

Республика ифтарында җәмәгать белән ахшам намазы да укылачак. «Ифтар – мөселманнарны берләштерүче мәҗлес. Һәм бу мәҗлескә без ашау-эчү өчен түгел, ә рухи ризык алу өчен җыелабыз», – диде Илфар хәзрәт матбугат очрашуында.

Ашау-эчү димәктән, быелгы ифтар кунакларына 600әр сумлык комплектлар әзерләячәкләр. Оештыру эшләрен башкару өчен, 16 яшьтән өлкән 500ләп волонтер чакырырга ниятлиләр. Ифтар үткәрүдә ярдәм итәргә теләүчеләр Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтында теркәлә ала.

> 30 апрельдә X республика ифтары кунаклары өчен Казан – Аэропорт – Казан маршруты буенча өстәмә шәһәр яны поездлары йөреячәк. Бу турыда Казан мэриясе хәбәр итте. Бу көнне мәҗлескә 7601, 7602, 7603, 7604, 7606 нчы номерлы поездлар белән барып җитәргә мөмкин булачак.

«Туган авылым» ресторан комплексы җитәкчесе, мәҗлесне оештыручыларның берсе Радик Габдрахманов сүзләренчә, ифтар бик «тәмле» булачак. «Бәяләрнең артуы йогынты ясамый калмады, билгеле. Ләкин бу ифтарның масштабын һәм «тәмен» үзгәртмәс дип уйлыйбыз. Менюда пылау, төрле камыр ризыклары, чәкчәк, яшелчә һәм җиләк-җимешләр, кипкән җимешләр, төрле эчемлекләр булачак», – дип сөйләде ул. Ризыклар әзерләү өчен 1 тонна дөге, 2 тонна сыер ите, 1,5 тонна яшелчә, 1 тонна җиләк-җимеш, 1 тонна кипкән җимешләр, 600 кг чәкчәк һәм башка әйберләр сатып алганнар. Чагыштыру өчен, 2017 елда узган республика ифтар мәҗлесе өчен 3 тонна пылау пешергән булганнар.

Быелгы ифтарның тагын бер яңалыгы – чакыру билетларының электрон рәвештә генә булуы. «Быел республика ифтарына чакыру билетлары кулга бирелмәячәк. Аларны без электрон рәвештә юллаячакбыз», – дип аңлатты Илфар хәзрәт. Билетлар мөхтәсибәтләр, мәчетләр аша биреләчәк. Ифтарда катнашу теләге булган кешеләр Диния нәзарәтенә гаризалар да юллый ала, аларны мөфтият җитәкчелеге караячак.

Мәҗлес нәшидләр һәм мөнәҗәтләр белән үрелеп барачак. Шулай ук ифтарда хәләл-маркет эшләячәк, хатын-кызлар өчен мөселман киемнәре тәкъдим ителәчәк, танылган дин әһелләре рамазан аеның фазыйләтләре турында вәгазьләр сөйләячәк. Моннан тыш, чарада дини гыйлем алу мөмкинлекләре белән танышып булачак.

Сүзгә-сүз

Олег КОРОБЧЕНКО, Дәүләт Советы депутаты, «Кориб» компаниясен гамәлгә куючы:

Бүгенге вазгыять безне көндәшләрсез калдырды. Базар чиста. Без хәзер эшләячәкбез дә эшләячәкбез. Бәлки, моңа бәйле рәвештә сыйфат бераз кимер. Әмма без җитештерү өлкәсен ныгытачакбыз, тармак институтларын булдырачакбыз. Соңыннан, базар ачылгач, без үзебезнең җитештерүчеләргә ярдәм итәргә тиеш. Моңа кадәр безнең икътисад моның белән шөгыльләнмәде.

(Татарстан Дәүләт Советының 31 нче утырышындагы чыгышыннан)

МАЙ ЯЛЛАРЫН КАЙДА УЗДЫРАЧАКСЫЗ?

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре Россия халкыннан шул хакта сорашкан.



Өйдә генә	55%
Бакчага барам	42%
Ил эчендә сәяхәт итәчәкмен	8%
Кавказ яисә Кырымга җыенам	3 һәм 2%

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Утырган ботакка балта чабып...

Кичә БМО гамәлгә куйган даталарның тагын берсе – Халыкара Җир көне билгеләп үтелде. Аны әле тагын Җир-ана көне дип тә атыйлар. «Кешелек» дип аталган үзенчәлекле һәм дә каршылыклы кавем яшәгән урын, цивилизация бишеге булган Җир бүген яклауга һәм саклауга мохтаҗ. Чөнки соңгы бер гасыр – гасыр ярым вакыт аралыгында планетабыз, дөрес хуҗалык итә белмәвебез аркасында, масштаблы үзгәрешләр кичерә. Алар барысы да диярлек – табигатьне, атмосфераны пычратуга бәйле кире үзгәрешләр. Җирнең кадерен беләбез, аны яратабыз, саклыйбыз, дип әйтер сәбәпләр әлегә юк. Кемнәрдер чаң какканда, икенче берәүләр аңа зарар сала. Бу хәлләр планетабыз тормыш итәргә яраксыз хәлгә килгәнче дәвам итмәсме? «Кеше» дип аталган биологик төрне барлыкка китереп, Җир-ана ялгышмаганмы?

Язлар җитеп, шәһәрдә тәрәзә, балкон аслары кардан ачылуга, кеше дип аталган «акыл иясе»нең чын йөзе дә ачылып киткән төсле була. Тора салып урамга атылган тәмәке төпчекләреннән башлап, полиэтилен капчыклар, төргәк калдыклары, төрледән-төрле шешәләр... Алар белән балкон аслары гына түгел, ишегаллары, бакча-скверлар, тротуарлар тулган. Үзең яшәгән тирәлекне үзең үк шулай чүпкә батыр инде. Бүгенге кешелекне «чүп цивилизациясе» дип тиккә генә атамыйлар шул. Һәм бу күренеш – безгә хас булган, «сансызлык» дип аталган айсбергның очы гына. Ярар, чүпне өмә оештырып җыеп та алырбыз. Ә менә миллионлаган машиналар, металлургия, химия, нефтехимия предприятиеләре чыгарган углекислый газны бик теләсәк тә җыеп ала алмыйбыз. Ул гынамы, шул ук машиналар саны, алар яккан ягулык, очырган төтен күләме елдан-ел арта тора. Монысы инде балконнан урамга атылган чүп кенә түгел...

Чит ил документалистлары төшергән фильмны карыйм. Илле процент ихтималлык белән шушы гасырда Европа климатында туачак глобаль, алай гына да түгел, катастрофик үзгәрешләр турында кисәтәләр. Дәлилләре җитди, үтемле. Парник эффекты, ягъни атмосферада углекислый газ артудан туган җылыну нәтиҗәсендә Гренландия бозлары зур тизлектә эри. Әле башта төшенеп бетмәдем. Гренландия кайда да, Европа кайда? Нинди бәйләнеш? Әмма бәйләнеш бар икән шул. Гольфстрим туктау алдында, дип кисәтә фильм авторлары. Үзәк Америка ярлары, Мексика култыгының миллиардлаган кубометр җылы суларын Британия утрауларына чаклы алып килеп, бөтен Европаны диярлек җылытып, уңайлы, көйле һава торышы тудырып торучы мәшһүр океан агымы шушы йөзьеллыкта юкка чыгарга мөмкин, ди алар.

Сәбәбе шактый гади. Европа ярларын җылытканнан соң, ул бөек агым, шактый суынып, көнбатышка борыла да, Гренландия ярларына җиткәч, бөтенләй температурасы кимеп, тыгызланган тозлы су океан төбенә төшеп китә. Төшә дә Мексика култыгына чаклы төптән, бер-ике чакрым тирәнлектән кирегә ага икән. Әлегә шулай. Тик Гренландия бозларының ел саен ныграк эрүе ул тирәдәге суны һаман да ныграк төчеләндерә. Төче су тозлы суга караганда җиңел, ул төпкә китми. Көньякка юнәләсе, төптән агасы агым яралмый кала. Төньяк Атлантикадан экваторга кадәр су әйләнеше бозыла, Европага җылы килми башлый. Һәм нәтиҗәдә Иске дөнья климаты бераздан Себер климатына әйләнәчәк, кыйтга тулысы белән туңачак, дип кисәтә фильм.

Углекислый газ күбәю сәбәпле туган «парник эффекты», глобаль җылыну ул температура күтәрелү генә түгел. Ул – галимнәр аңлатканча, Җирдәге климатның кискенләшүе. Кайдадыр – моңарчы күрелмәгән салкынаю, икенче бер тарафта – киресенчә, ләүкә климаты яралу, кайдадыр – дәһшәтле корылык, башка урында – күрелмәгән су басулар. Тайфун-торнадолар, дистәләрчә мең кешенең гомерен кисүче цунамилар. Болар барысы да – табигатьне санга сукмаган эгоистик техноген цивилизациянең гөнаһлары аркасында туган һәм туачак гарасатлар. Моны белеп, күреп торып та, бернинди чара күрмәүне ничек аңларга? Ихтимал, аерым затның гына түгел, кешелекнең дә бүгенге көн белән, иртәгә өчен ишәк кайгырсын, дип яшәве, ягъни «глобальләшкән сансызлык» дип аталган, бүгенге цивилизациягә куелган диагноз сәбәпчедер.

Атмосфераны агулаучы, пычратучылар булып, беренче чиратта, сәнәгать предприятиеләре, авыл хуҗалыгында аммиаклы ашламалар куллану һәм автотранспорт торса, климатны бозуда төп гаепле – әлбәттә инде, без телгә алган, без әллә нигә санаган автомобиль. Узган гасырның 70 нче елларында төтенле шул хәрәкәт чарасының Җир экосистемасына китергән зарары гомуми зарарның 15 процентын тәшкил итсә, бүген ул өлешнең 60 процентка якынлашуы мәгълүм. Комфортка мөкиббәнлекнең шактый кыйммәткә төшкәнен аңлар өчен, Автомобиль җитештерүчеләр халыкара ассоциациясе 2015 елда игълан иткән статистикага карыйк. Җир йөзендә ул елда җәмгысы 947 миллион җиңел, 335 миллион йөк автомобиле булган. Шул ук оешма хәзерге көндә елына якынча 90–100 миллион яңа авто җитештерелүен билгели. Кытай үзе генә дә елга 25 миллион авто ясый икән. Барысын бергә кушып санаганда, автомобильләрнең гомуми саны бүген 1,8–2 миллиардка (!) якынлаша булып чыга. Күз алдына китерү дә кыен!

Һавага ыргытылган углекислотага кайтып, аның 72 процентын бүген нәкъ менә автотранспорт чыгарганын белгән хәлдә, үз-үзебезгә ел саен биреп килгән ул «бүләк»нең гомуми массасын да чутлап куйганнар. Бер ел эчендә планетада җитештерелгән машина төтененең гомуми авырлыгы якынча 7 миллиард тонна икән. Физикадан бер килограмм CO_2нең 500 литр күләм биләве билгеле. Димәк, автомобильләр атмосферага өргән газның күләме – 3,5 триллион кубометр!

Кешелек бишеге булган Җир, галимнәр исәпләп чыгарганча, Кояш тирәли инде менә 4,5 миллиард ел буе әйләнә. Озын-озак дәверләр буе анда үсемлекләр үсә, тере җан ияләре яши, үрчи. Аларның бер генә төре дә дистә, йөз миллион еллар дәвамында табигатькә зыян салмаган. «Кеше» дигән зат та техника, технология үскәнче зарарсыз булган. Бүген исә ул Җирдә чын мәгънәсендә корткычлык алып бара. Ул урманнарның яртысын кисеп бетерде, ул елдан-елга күбрәк углеводородлар яга, җир өслеген генә түгел, океан төпләрен дә пластик чүбе белән тутыра. Болар барысы да санаулы вакыт аралыгында, 100–150 ел эчендә эшләнә. Тагын 100 елдан ни булыр? Үзебез утырган ботакка яшәгән саен ярсыбрак балта чаба торгач, мәтәлеп, үзебез белән бергә бөтен биосфераны, Җирне дә харап итмәбезме? Сораулар ачык кала.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

tatarstan.ru

Берничә хезмәткә – бер карта. «Мир» түләү системасы нигезендә яңа проект булдырырга җыеналар. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов шул хакта «Мир» түләү системасы генераль директоры Владимир Комлев белән очрашуда сөйләште. Очрашу Хөкүмәт йортында узды.

Ике як та хезмәттәшлекне үстерү буенча яңа һәм уртак проектлар турында фикер алышты. Аерым алганда, Татарстан Президенты белән Владимир Комлев «Татарстанлы картасы» проектын тормышка ашыру мәсьәләсенә тукталды.

«Мир» түләү системасы нигезендә булачак әлеге карта нәрсәдән гыйбарәт соң? Аның буенча түләү башкару һәм кайбер социаль әһәмияткә ия хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеге булдыру күздә тотыла. Әйтик, электрон юл йөрү билеты, медицина иминияте полисы, СНИЛС һәм башка рәсми документларны туплау.

– Күп кенә өлкәләрдә цифрлы хезмәтләрне актив рәвештә гамәлгә кертүче алдынгы төбәк белән без «Мир» картасы нигезендә киң социаль әһәмиятле хезмәтләр җыелмасын туплаган заманча проект булдырырга ниятлибез. Халык өчен кирәкле саналган һәм ихтыяҗ булган цифрлы продуктларны саклап та калачакбыз, аңа яңа мөмкинлекләр дә өстәячәкбез. Әйтик, «Мир» картасын социаль ярдәм чараларыннан, мәдәният, сәламәтлек, спортка бәйле хезмәтләрдән файдалану коралы итәчәкбез. Төбәк халкы өчен чынлап та уңайлы проект булыр дип өметләнәм, – дип шәрехләде очрашуны Владимир Комлев.

Сүз уңаеннан, 2021 елда «Мир» картасын кулланып, товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә 182,5 млрд сумлык 297 млн түләү башкарылган. Үсеш күрсәткече, 2020 ел белән чагыштырганда, 45 процентны тәшкил итте.

* * *

Рөстәм Миңнеханов бу көнне туризм һәм шушы тармак инфраструктурасын үстерү буенча Дәүләт Думасы Рәисе Сангаджи Тарбаев белән бу өлкәгә бәйле ярдәм чаралары турында фикер алышты.

Аерым алганда, Президент Татарстандагы туризм тармагының үсеш юнәлешләре турында сөйләде. Татарстан Президенты республиканың «Идел сәяхәте» проектында катнашуы турында да әйтте. Хөкүмәт йортында узган чарада республиканың туризм буенча дәүләт комитеты рәисе Сергей Иванов һәм Татарстан Президенты ярдәмчесе Олеся Балтусова да катнашты.

Юл хакы акланырмы?

Бәя арту аны гына урап узмас инде. Юл хакы турында сүзебез. Бу елның маеннан җәмәгать транспортында йөрү берничә сумга артачак. Моның сәбәбе нәрсәдә һәм юл хакы күпме булачак?

1 майдан Казанда җир өсте җәмәгать транспортында йөрү хакы бер сумга артачак. Татарстанның автотранспорт предприятиеләре ассоциациясендә белдерүләренчә, тариф үзгәреше уртача инфляциядән артык түгел.

– Юл хакын үзгәртү өчен сәбәпләрне Татарстанның тарифлар буенча дәүләт комитеты өйрәнде. Нәтиҗәдә акча яки банк картасы белән түләгәндә юл бәясе 3 процентка арта, ә транспорт картасы белән түләүне дә исәпкә алып, гомуми арту 9 процентны тәшкил итәчәк. Бу инфляциянең уртача дәрәҗәсенә туры килә, – диелә ассоциация аңлатмасында.

Җәмәгать транспортында йөргән өчен түләүне арттыру турындагы мәсьәлә белән Казан Транспорт комитетына һәм Татарстанның тарифлар буенча дәүләт комитетына мөрәҗәгатьләрендә алар сәбәп итеп пассажирлар саны һәм, коронавирус пандемиясе аркасында, транспортта QR-код системасын керткәч, табышның бермә-бер кимүен күрсәткән.

Мәгълүм сәбәпләр аркасында, ягулык-майлау чималы, запас частьлар, шиннар кыйммәтләнү, транспортны яңарту да таләп ителгәнлектән, тарифны арттыру турында карар кабул ителде.

Шулай итеп, без нинди юл хакына әзер торырга тиеш соң? 1 майдан Казан җәмәгать транспортында (автобус, трамвай, троллейбус) юл бәясе – 36 сум, банк һәм транспорт картасы белән түләгән очракта 31 сумны тәшкил итәчәк.

Үзгәреш җиле Әлмәт, Түбән Кама һәм Минзәлә шәһәрләренә дә кагылачак. Әлмәт белән Түбән Камада юл хакы 28 сумны тәшкил итәчәк. Минзәләдә барлык категория гражданнар өчен юл бәясе 20 сум булачак.

Шунысын да искә төшерик: соңгы тапкыр Казанның җәмәгать транспортында йөрү бәясе 2021 елның мартында 30 сумнан 35 сумга кадәр артты. Транспорт һәм банк карталары буенча тарифлар 2020 елның 1 гыйнварыннан үзгәрешсез кала бирде (27 һәм 30 сум).

▶ 2020 елда пассажирлар агымы, 2019 ел белән чагыштырганда, 30 процентка кимегән: 260 миллион кешедән 183 миллионга калган.
▶ 2021 елда Казан автобусларында 206 миллион кеше йөргән.

Дуслык һәм тынычлык булсын

Бүгенге катлаулы вазгыятьтә республикада дустанә мөнәсәбәтләрне саклау, күпмилләтле халкыбызның игелекле, шәфкатьле, ярдәмчел булуы аеруча мөһим.

tatarstan.ru

Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясы советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин ассамблея советы президиумы күчмә утырышында шулай диде. Утырыш Алабугада туган телләрне саклау һәм үстерү мәсьәләләренә багышлап үткәрелде.

Халыклар ассамблеясының шәһәр-районнардагы күчмә утырышлары инде күптән матур традициягә әйләнде. Милли-мәдәни берләшмәләр вәкилләре, ассамблея филиаллары һәм вәкиллекләре җитәкчеләре, Дуслык йортлары директорлары, министрлыклар һәм ведомстволар, муниципаль хакимият вәкилләре мондый чараларда милләтара мөнәсәбәтләрне ныгыту өлкәсендә тәҗрибә уртаклаша.

– Алабугада телләрне, күпмилләтле халыклар мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерүгә, яшь буында милләтара тынычлык-татулыкка карата ихтирам хисе тәрбияләүгә зур игътибар бирелеп килә. Нәкъ менә муниципаль берәмлекләрнең этносара мөнәсәбәтләрне ныгытуда зур роль уйнавына иманым камил, – диде Фәрит Мөхәммәтшин, муниципаль җитәкчеләргә мөрәҗәгать итеп. – Сезнең җирлектәге хәлләрне сездән башка яхшырак белүче юк. Милләтара тынычлык һәм татулыкны саклауга керткән өлешегез гаять зур. Иң элек бер-береңә, хакимият органнарына ышаныч дигән сүз бу.

Агымдагы ел Татарстан Халыклар ассамблеясы өчен юбилей елы булып тора. Иҗтимагый оешма үзенең 30 еллыгын билгеләп үтәчәк. Шул ук вакытта 2022 ел илебездә Россия халыкларының мәдәни мирасы елы буларак игълан ителде. Моннан тыш быел Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулуны билгеләп үтәчәкбез. Парламент башлыгы әйтүенчә, әлеге чарага 4 меңнән артыграк кунак көтелә.

Фәрит Мөхәммәтшин Луганск, Донецк халык республикалары һәм Украина территорияләрендә махсус хәрби операциягә бәйле вазгыятькә һәм моңарчы күрелмәгән санкцияләр кертелүгә дә тукталып үтте. Аның әйтүенчә, килеп туган шундый катлаулы шартларда республикада дустанә мөнәсәбәтне саклау, күпмилләтле халкыбызның изге күңелле, шәфкатьле, ярдәмчел булуы аеруча мөһим. «Бүген безгә бердәмлек, дуслык, тынычлык кайчандагыга караганда да күбрәк кирәк. Без бердәм булырга тиеш», – диде Дәүләт Советы Рәисе.

Татарстан милли-мәдәни берләшмәләре вәкилләре ДНР һәм ЛНРда яшәүчеләргә, республикага мәҗбүри күченүчеләргә хәйрия акцияләрендә актив катнаша. Татарстаннан барлыгы 100 тоннадан күбрәк гуманитар ярдәм белән 8 йөк машинасы шул тарафларга озатылган. Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, ассамблея әгъзалары да бу изге эштә хәлдән килгәнчә өлеш керткән.

Күчмә утырышта туган телләрне саклау һәм үстерү мәсьәләсе көн тәртибендәге төп мәсьәләгә әйләнде. Күпмилләтле Алабуга районында бу мәсьәлә дәүләт сәясәтендә өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып тора. Хәзерге вакытта районда руслар (50 проценттан артыграк), татарлар (43% чамасы), мари, чуаш, удмуртлар һ.б. яши. 2014 елдан бирле анда туган телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерүгә юнәлдерелгән муниципаль программа тормышка ашырылып килә.

Утырышта катнашучылар «Адымнар» Алабуга күптелле мәгариф комплексында һәм 1 нче гимназия үрнәгендә район мәктәпләрендә укучыларның туган тел байлыгын, милли мәдәниятне һәм традицияләрне ничек өйрәнүләре белән танышты. Алабуганың туган телләрне үстерү һәм саклау тәҗрибәсе уңай бәяләнде.

«ВТ» архивыннан

БӘХЕТ ТАГЫН ЕЛМАЯ

Бакчачыларга тагын бәхет елмаерга тора. Росреестрның Татарстан бүлеге хәбәр итүенчә, бакчачылык, яшелчәчелек белән шөгыльләнү яки дача хуҗалыгы алып бару өчен тәгаенләнгән җир кишәрлеген бушлай рәсмиләштерү 2031 елның 1 мартына кадәр озайтылырга мөмкин. Бу хактагы закон проекты Россия Дәүләт Думасында карала.

Белгәнебезчә, әлеге срок 2022 елның 1 мартына билгеләнгән иде. Әмма гражданнардан җирләрен бушлай рәсмиләштерергә теләүләре турында гаризалар һаман да килеп тора икән әле. «Бүген Татарстанда күп кенә бакчачыларның әгъза булулары турындагы кенәгәдән кала бернинди документлары да юк, – ди бу җәһәттән Татарстан буенча Росреестр идарәсе җитәкчесе Азат Җәббаров. – Алар җирләрен ни сәбәпледер һаман да рәсмиләштерә алмаганнар. Монда, кагыйдә буларак, совет вакытында алынган участоклар турында сүз бара. Хәзер инде, срогы беткәч, җирне үзенеке итәргә теләүчеләр күбәеп китте, нишләрбез икән дип кайгыра башладылар. Яңа закон аларга бу эшне ахырына җиткерергә ярдәм итәр дип ышанабыз».

Әнә шуңа күрә дә белгечләр артык кайгырмаска, яңа законның гамәлгә кергәнен көтеп торырга кушалар. Яңалыклар моның белән генә бетмәячәк әле. Яңа документ нигезендә җирне рәсмиләштерүне күпкә гадиләштерергә җыеналар. Ә тавыш бирү телефон яки башка берәр элемтә чыганагы аша да үткәрелергә мөмкин. Бу гамәлнең дә уңай ягы бар, чөнки бакчачылык ширкәтләрен алып баруда төп инструмент – ширкәт әгъзаларының гомуми җыелышы. Гадәттә мондый җыелышларга күпләр килеп тормау ягын карый. Күрәсең, вакытларын әрәм итәсе килмидер. Соңгы вакытта килеп чыккан пандемия дә тискәре йогынты ясады. Бер урында күпләп җыелуның, чыннан да, куркыныч яклары юк түгел. Нәтиҗәдә ниндидер карар кабул итү өчен күп вакытта кворум җыела алмады.

Кайбер мәсьәләләрне яхшыртуны күздә тотып, төбәк дәрәҗәсендә дә закон проекты карала. Татарстан Дәүләт Советында әйтүләренчә, республикада коммерцияле булмаган бер меңнән артык бакчачылык берләшмәсе бар. Алар үзләренә миллионлаган татарстанлыны берләштерә. Соңгы биш елда гына бакчачылык һәм яшелчәчелеккә ярдәм итү өчен 2 млрд 750 млн сум акча бүлеп бирелгән. Быел ул – 550 млн сум. Шулай ук субсидия бирү механизмы да эшләп килә. Закон чыгаручылар фикеренчә, боларның барысы да республикада бакчачылыкны үстерүгә һәм халыкка үз ихтыяҗларын канәгатьләндерергә яхшы шартлар тудырачак.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

БЕЛГЕЧНЕ НИЧЕК САЙЛАРГА?

Яз килүгә, халык кадастр эшләрен планлаштыра башлый: җир участокларының чикләрен билгели, мәйданын тәгаенли, капиталь төзелеш объектларының урынын ачыклый. Бу эшләрне үткәрү нәтиҗәсендә заказ бирүчегә ызанлау планы яки техник план, шулай ук тикшерү акты тапшырыла.

Росреестрның Татарстан бүлегендә әйтүләренчә, техник документлар күчемсез милекне рәсмиләштергәндә, объектны кадастр теркәвенә куйганда яки, киресенчә, аннан төшергәндә, шулай ук төрле үзгәрешләр керткәндә (мәсәлән, бинаның мәйданы үзгәртелсә) кирәк булачак.

Әлеге эшләрне башкару өчен, кадастр инженерын чакыртырга кирәк. Мондый белгечләр шәхси эшмәкәр дә, юридик зат вәкиле дә булырга мөмкин. Һәр очракта да кадастр инженеры үзкөйләнешле оешмада әгъза булып торырга тиеш. Башкача булганда, кадастр эшләрен үткәрергә хокук бирелми. Ялган юл белән эшләсәләр дә, әзер документлар юридик көчкә ия булмый.

Бүген республика территориясендә бу өлкәдә 600ләп кеше хезмәт куя. Белгечне сайлауда кыенлыклар туса, Росреестрга мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Белешмә өчен: җир участокларының мәйданы ачыкланган булу – бу кишәрлекнең чикләре гамәлдәге законга тәңгәл китереп билгеләнгән дигән сүз.

КӨТҮ АЛДЫННАН



«ВТ» архивыннан

Авыл хәлләре

Беренче карашка авылда иң эшсез, иң рәхәт вакыт бу. Көн саен йә кар, йә яңгыр ява, өйдә әллә ни эш юк, бакчага-кырга чыга торган түгел. Кояш карап, җирләр кипшерә башласа, бөтенесе җепкә тезелгәндәй китәчәк анысы. Әмма «үткән елгы эшнең быелга калганы юк әле, бетәр» дибез дә булган көннәргә шөкер итәбез. «Бу кыш китәсе булмады быел, тагын кар яуган инде», – дип, болай гына зарланабыз лабаса. Язгы карларның, язгы яңгырларның тамчысына кадәр кадерле икәнен генә чамалыйбыз ла.

Хәер, беренче карашка гына авылда үле тынлык кебек тоела бу чор. Язгы кызу эшләргә кадәр дип ваклы-төякле әллә никадәр эшләр майтарыла, үзенә көндәлек эш-мәшәкатьне табып тора авылнылар, димәкче булам. Әнә кемнәрдер карт тавыкларын яшьрәк чебешләргә алыштыра. Ике елдан да артып китсә, йомырка күрәм димә. 3–4 айлык чебешләрне районда әллә ничә урында саталар, шалтыратасың гына, китереп бирәләр: агы кирәкме, чуарымы, нәселлесеме.

Алданрак аяк киенергә яратучылар бу көннәрдә бройлерлар да алды инде.

– Февраль башында ук бер айлык чебешләргә заказ биреп, акчасын түләп куйдык, бәяләре дә чагыштырмача очсыз булды, чебешләре дә күз тимәсен дия торган, – диюче танышлар байтак. Кемдер утызны алган, 70, 100, 150гә кадәр чебеш алучылар бар икән. Күпләп алучылар, билгеле, үзләре өчен генә үстерми, кәсеп итеп, сатарга күнегүчеләр. Андыйлар да елдан-ел арта дип беләм. Нигә, алучы бар икән, эштән курыкмыйсың икән, сатудан беркем дә тыймый. Әле берничәшәр партия чебешен, казын, үрдәген үстерәләр. Җаен белгән кешегә җайлыдыр да... Тик көннәр суытып җибәргәч, уңайлы дип саналган ояларда да бер айлык чебешләргә салкын була шул. Алар бу яктан шактый нәзберек: чирләп калмасыннар өчен төнлә дә, саклык чарасын күреп, махсус лампалар яндырырга мәҗбүр хуҗабикәләр. Билгеле инде, андыйлар төн йокысы күрми (ни дисәң дә, саклык артык булмый). Сәхәргә кадәр дә, аннан соң да әллә ничә кабат карыйбыз, диләр.

Җылыту димәктән, күрше авылдагы танышларым исә, башка елны бу вакытта үсентеләрне савытлары белән теплицага күчерә идек, көннәр дә әллә ни салкын түгел дип, быел да чыгарган булганнар. Иртән торып чыксак, бар дөнья ап-ак кар, кире алып кердек, диләр. Ә икенче бер танышларым шулай ук җылытылмаган теплицага бөтен үсентеләрен күчереп бетергән (савытлары белән, әлбәттә). Өйдә озынаеп беттеләр, көндез дә, төнгә дә берничә урынга чиләк белән кайнар су куябыз, теплица май кебек була, төнгә дә суынып бетми, үсентеләр дә хәл алды, дип сөенә. Мәшәкате булса да, үзе дигәнчә эшли инде сала кешесе. Үсентеләр турында сүз чыккан икән, бу чорда авылда гөлләргә рәт-чират бик калмый: аларның мәңгелек урынын – тәрәзә төпләрен помидор, баклажан, борыч, чәчәк һәм башка үсентеләр «басып» ала. Яктырак, салкынчарак урынга дип аларга өстенлек бирә хуҗалары. Авылларда аларны быел гына күпләп утыртканнар димәс идем, башка елларда да әле шәхси хуҗалыклардан тыш, балалар бакчалары, мәктәпләр үз бакчалары өчен дә, сораучылар өчен дә аларны бездә күпләп утырта.

Март ахырларында елгада су кузгала башлауга, район авылларында шактый кешеләрнең базларына, өй асларына су керә башлый. Андыйлар алдан-ала чарасын күреп, бәрәңгеләрен башта сәндерә ясап күтәртә, аннан лапас-абзар тирәсенә, җылырак-ышыграк урынга чыгара. Алар гына түгел, «Вакыт җиткән инде, бу карлар кояш бер карауга эреп бетәчәк, җирдә туң юк, җир тиз әзер булачак, бәрәңгеләр яровойлашып бетә алмый», – дип тә бәрәңге чыгаручылар бар икән инде. Бакчасы иртәрәк җитешә торган кешеләр шулай эшлидер, әле күбебезнең бәрәңгесе базда.

Авыл, яз дигәндә авыл урамында челтерәп аккан гөрләвекләр, шул суда түшен суытырга чыккан, ояда утыручы ана казлар һәм аларны күргән сөенечтән каңгылдап йөрүче ата казлар күз алдына килә иде. Быел беренчесе дә булмады, әллә шуңа, әллә инде тирә-күршеләр дә казларын бетергән, урамда казлар да күренми. Моңа кадәр әле бездә берничә кеше булса да ана казлар асрый, кунакка килүчеләр: «Кара, сездә казлар да бар икән», – дип гаҗәпләнә иде.

Язгы эшләрдән әлегә печән җирләренә тырмаларга кереп булмый, әмма аларга өстәп яки яңартылган җирләргә чәчәргә орлык эзләүчеләр дә, ашлама сораучылар да күренгәли инде. Шул ук вакытта авыл кешесе чираттагы төзү-яңарту эшләренә дә әзерлекне башлады: бу чорда төзелеш материаллары туплап куярга гадәтләнгән алар, бәяләр арту гына кешене бу ниятеннән туктатмый.

Хуҗалык игенчеләре, механизаторлар да бу көннәрдә Сабан туен көткән чабышкыга тиң. «Башка елны бу вакытта...» – дип, инде алар язның ничә көнгә соңарганын саный. Кар бетәр-бетмәстә, төнге-иртәнге каткакта уҗым, күпьеллык үлән басуларына төрле агрегатлар белән ашлама кертәләр иде шул. Быел заманча «Туман»нар да басуга керерлек җай булмады. Кар бетә барса да, җир төннәрен дә катмады. Хәер, бер башлагач, кырдагылар да көне-төне эшли, дым югалганчы дип, бөтенесен вакытында үтәп чыгар өчен тырыша анысы.

Соңгы көннәрдә бездә, мөгаен, абзардагы маллар да көтүгә чыгар чаклары җитәсен исенә төшергәндер. Кыш буе тынып торган ветеринария табиблары, авылларда йөреп, көтүгә чыгарга рөхсәт бирү өчен кан алды, нәрсәгәдер каршы укол кадады. Ярый әле, быел үткән елдагы кебек, каннарны пробирка белән үзең клубка, клуб булмаган авылда мәчеткә илтеп бирәсе булмады. Әмма эш көнендә, эш вакытында кан алулары өендә пенсионеры булмаган кешегә бер матавык (өйдә һич югы сыер малын күрсәтерлек кеше булырга тиеш). Әле дәвамы да бар: әнә шул кан алдыру өчен акча түләгән квитанцияң белән күрше авыл мәдәният йортына дәүләт ярдәмен алу һәм түләгән акчаны кире кайтару өчен килешү төзергә барасы бар. Анысы да гадәттәгечә эш көнендә, эш сәгатендә. Соңга калсаң, ветучастоклар урнашкан авылларга барасың була, диләр. Әле анда паспорт, ИНН, саклык кенәгәсе... белән барасы, ике данәдә су буе кәгазь тутырасы... Үткән ел гына шуларны тутырдык лабаса! Үзгәреш булган кешеләр генә язса да булмыймы икәнни?! Бөтен мәгълүмат компьютерга кертелә диләр дә, ел саен шушы хәл кабатлана... Зарлану кебек тоелса да, урынлы зар бу. Мәшәкатеннән туеп, артыннан йөрмәүчеләр дә бар. Юкса бу ярдәмне гади формада да оештырып булыр иде.

Оештыру димәктән, быел ураза искитмәле көннәргә туры килде: эссе дә түгел, салкын да түгел, эш-мәшәкать тә әллә ни юк. Шуңадырмы, авылларда ураза тотучылар да күп, мәчетләргә тәравихка йөрүчеләр дә шактый. Аерым кешеләр, хуҗалык-оешма җитәкчеләре, шәхси эшмәкәрләр, зурдан кубып, авыз ачтырулар оештыра. Аларына да бик бердәм булып, сөенеп катнаша авыл халкы.

Шушы язманы әзерләгәндә генә «Ватсап»тагы авыл төркеменә авыл җирлеге башлыгыннан белдерү килеп төште: «Бу атнада, 23–24 апрель көннәрендә, зиратларда өмәләр үткәрелә. Һәр хуҗалыктан бер кеше булу мәҗбүри», – диелгән. Әйтәм бит, көнгә-һава торышына карамый, авыл кешесе үзенә эш-мәшәкатьне табып тора ул. Эше дә табылып тора...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Менә шундый кеше

Хат ташучы Гөлнара

Зарлана белми. Оптимист. Теле – аралашуга, кулы эшкә ятып тора. Буада хат ташучы булып эшләүче Гөлнара Кадыйрова турында хезмәттәшләре әнә шулай ди. 15 елдан артык эшен яратып башкара ул. Әбунәчеләре дә үзен көтеп кенә тора. Кешеләр белән уртак тел тапканга, эше дә җайлы бара.

– Без элек Кырык Садак авылында яши идек. Анда да сигез ай хат ташучы булып эшләдем. Аннары инде ирем белән район үзәгенә күчәргә уйладык. Буага килгәч тә, нинди эшкә урнашыйм дип баш ватмадым, үз эшемне таптым, – ди ул. – Күп еллар бер урында эшләгәч, үзем хезмәт күрсәтә торган кешеләр белән дуслашып беттек. Мин дә якын итәм үзләрен, алар да хөрмәт итә. Менә шул хөрмәт эшләргә көч бирә дә инде. Гаиләм, ирем белән ул-кызларым да эшемне аңлады. Мин бит көннәр буена кайтып кермим кайчак.

Гөлнара ханым кул эшләренә дә оста. Вакыт булганда, бәйли дә.

– Бакча эшләрен дә бик яратам. Монда фатирда торгач, ял саен авылга кайтып йөрибез. Авылда бакчабыз бар. Бакчачылык турында «Ватаным Татарстан» газетасыннан укыйм, – ди Гөлнара Кадыйрова. – Басманы бик яратып укыйбыз. Халык үзе сорап яздыра. Мин дә, аларга бераз файда булсын дип, ташламалы вакытта өйләренә барып яздыртам. Пенсия дә таратам, коммуналь хезмәтләр өчен дә акча җыям. Аллага шөкер, иренмим. Бездә кешеләр әйбәт. Берәү дә кире бормый.

Никадәр эше күп булса да, Гөлнара ханым газета укырга көненә кимендә 15 минут вакыт таба.

– Мин инде үземне башка эштә күз алдына да китерә алмыйм. Шулкадәр яратып эшлим. Яшьләрне безнең эшкә өйрәтергә иде ул. Хезмәт хакын вакытында бирәләр. Акчасы аз дип булмый. Мин бер дә зарланмыйм. Эшли белсәң, акчасы да җитә. Артып та кала әле. Иң мөһиме – теләк кирәк, – ди ул.

Гөлнара ханым тормышыбызга интернет килеп кереп харап итте, дип кенә уфтана.

– Элек туганнар хат алыша иде. Бәйрәмнәрдә открыткалар языштылар. Бу гадәт юкка чыкты. Берәү дә хат язмый хәзер. Шуңа эчем поша. Ә бит ул хатларда күпме җылылык иде! Телефон аша җибәрелгән котлау – котлаумыни ул! Хатлар бөтенләй юкка чыкты дип әйтеп булмый инде анысы. Машина йөртүчеләргә «сәлам» хатлары килгәләп тора, – ди ул. – Шөкер, газета укучылар да бар. Киләчәктә тагын да күп булырлар дип тә фаразлыйм. Ник дигәндә, халыкка рухи азык елдан-ел күбрәк кирәк!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз беренче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утыз беренче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
3. 2021 елда Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында хисап.
4. Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге оешмалар тарафыннан 2021 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре һәм әлеге оешмаларның эшчәнлеген камилләштерү буенча күрелгән чаралар турында мәҗбүри гавами хисабы.
5. Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрелүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинга теләктәшлек белдерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате.
6. «2021 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында» Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы доклады.
7. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 22 статьясындагы 3 пунктының гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 288-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 287-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 23 һәм 24 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 292-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 284-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
11. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 283-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
12. «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 286-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
13. «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарларын, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» 289-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
14. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 15 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 291-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
15. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәреш кертү хакында» 290-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
16. «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» 285-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
17. «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2^1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 293-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
18. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 78299-8 номерлы федераль закон проекты хакында («Бердәм дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында гомуми җыелышның көн тәртибе мәсьәләләре буенча тавыш бирү мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә).
19. «Күпфатирлы йортлар һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 11 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 77890-8 номерлы федераль закон проекты хакында (өлешләп төзүдә катнашу шартнамәсе буенча таләп итү хокукы бирү шартнамәсен дәүләт теркәвенә алу турында).
20. «Россия Федерациясе Тимер юл транспорты уставы» Федераль законның 83 статьясына үзгәреш кертү хакында» 94415-8 номерлы федераль закон проекты турында (шәһәр яны поездларында 7 яшькә кадәрге балаларны түләүсез йөртү хакында).
21. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 83061-8 номерлы федераль закон проекты хакында (озак сроклы инфраструктура проектларын гамәлгә ашыру һәм аларның хосусый инвесторлар өчен инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру өчен дәүләти-хосусый партнерлык механизмнарын камилләштерү өлешендә).
22. «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законның 95 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 84812-8 номерлы федераль закон проекты турында (җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкаруга контрактларны үзгәртү механизмын төгәлләштерү өлешендә).
23. «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» 72939-8 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт (муниципаль) учреждениеләре җитәкчеләре вазыйфаларын биләүче затлар өчен башка түләүле вазыйфалар биләүне һәм башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнүне тыю билгеләү өлешендә).
24. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 76647-8 номерлы федераль закон проекты хакында (коррупциягә каршы көрәш өлкәсендәге законнарны камилләштерү өлешендә).
25. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 89661-8 номерлы федераль закон проекты турында (күмерне күчерү, ваклау һәм сортларга аеру эшчәнлеге өлкәсендәге күрсәтмәләрне үтәмәгән өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә).
26. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 85708-8 номерлы федераль закон проекты хакында («Сколково» инновация үзәге территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыра торган югары белем бирү мәгариф оешмалары тарафыннан югары квалификацияле фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләүне, гыйльми дәрәҗәләр бирүне камилләштерү өлешендә).
27. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү хакында» 86110-8 номерлы федераль закон проекты турында (гамәли әзерлек оештыру өлешендә).
28. Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары биналарын капиталь ремонтлауның федераль программасын эшләү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Урынбасары Т.А. Голиковага Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате турында.
29. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 21 апреле
№ 1406-VI ДС

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы итеп чикләнмәгән срокка түбәндәгене сайларга:

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Идел буе суд районы буенча:

1 нче суд участогына – Знатнова Гөлнара Мулланур кызын.

2. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә сайланган Знатнова Гөлнара Мулланур кызының Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вәкаләтләре чоры элеккеге вәкаләтләр чоры тәмамланган көннән башлана.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 21 апреле
№ 1407-VI ДС

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет суд районы буенча 8 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында

«Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законының 7^1 статьясы һәм «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет суд районы буенча 8 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкаруны бер елга отставкадагы судья Васильева Марина Робертовнага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 21 апреле
№ 1408-VI ДС

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе **Җәббаров** Азат Галимҗан улы **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Александр Невский ордены** белән бүләкләнде.

***

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары **Мөхәммәдиев** Рөстәм Нәбиулла улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» I дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Мәдәният өлкәсенә югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе һәм нәтиҗәле фәнни-педагогик эшчәнлеге өчен «Казан дәүләт мәдәният институты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры **Әхмәдиева** Роза Шәйхәйдәр кызы; финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе урынбасары **Гайсина** Роза Салих кызы; «Алойл» ябык акционерлык җәмгыяте генераль директорының икътисад һәм финанслар буенча урынбасары – баш бухгалтеры **Галимова** Илгизә Фатыйх кызы; җитештерүдә югары күрсәткечләргә ирешүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Кама-Идел «КВАРТ» резин-техника акционерлык җәмгыяте» акционерлык җәмгыятенең 102-8 номерлы цехы пресслаучы-вулканлаштыручысы **Галимова** Гадилә Бари кызы; «Нурлат автотранспорт предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыятенең токаре-электр һәм газ белән эретеп ябыштыручысы **Пимулин** Евгений Елизарович; яшь буынга хәрби-патриотик тәрбия бирүгә һәм югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә өлеш кертүе өчен «Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Казан Суворов хәрби училищесы» федераль дәүләт казна гомуми белем бирү учреждениесе башлыгы урынбасары (инновацияле мәгариф технологияләре буенча) **Гаюн** Андрей Дмитриевич; күпьеллык намуслы хезмәте, республикада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү системасын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең Буа филиалы бүлеге башлыгы **Гонджуа** Людмила Александровна; республиканың юл-транспорт комплексын үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе директоры **Данилов** Эдуард Юрьевич; кадрлар сәясәтен гамәлгә ашыруга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының кадрлар бүлеге башлыгы **Сафина** Дания Мидхәт кызы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, республиканың тарихи һәм мәдәни мирасын саклауга зур өлеш кертүе өчен «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениесе директорының эксплуатация эше буенча урынбасары **Сафиуллин** Тимур Фәрит улы; республиканың агросәнәгать комплексына югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе һәм нәтиҗәле фәнни-педагогик эшчәнлеге өчен «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең тракторлар, автомобильләр һәм технологик процессларның куркынычсызлыгы кафедрасы мөдире **Хафизов** Камил Габделхак улы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республиканың азык-төлек һәм эшкәртү сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «ЧАЛЛЫ ИКМӘГЕ» акционерлык җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары **Юнысов** Эдуард Рафаэль улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең 15 номерлы филиалы – Казанбаш авылы китапханәсе мөдире **Әүхәдиева** Рузилә Равил кызына, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең 43 номерлы филиалы – Яңа Кырлай авылы китапханәсе мөдире **Әхмәтҗанова** Наилә Наил кызына, «Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең И.И. Шишкин музей-йорты мөдире **Башкирова** Лариса Львовнага, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе укытучысы **Вилданов** Фәйзелхак Габделхак улына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Балык Бистәсе туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Гарипова** Гөлфия Шириаздан кызына, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Чирмешән авылара үзәк китапханәсе» муниципаль бюджет учреждениесенең 1 номерлы филиалы – Аккирәй авылы китапханәсе мөдире **Ефимова** Ольга Ивановнага, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Исток» яшьләр клублары берләшмәсе» муниципаль бюджет учреждениесенең өстәмә белем бирү укытучысы **Кудрявцева** Марина Анатольевнага, Саба муниципаль районының «Саба үзәкләштерелгән авыл клублары системасы» (Район мәдәният йорты) муниципаль бюджет учреждениесенең 13 номерлы филиалы – Кече Шыңар авылы мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе **Рабгетдинова** Гөлсем Әхәт кызына, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе укытучысы **Солтанова** Наталья Александровнага, «Казан театр училищесы» (техникумы) дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Хәйбуллина** Адилә Илгиз кызына **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының юридик бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Верхова** Ирина Александровнага; Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Әтнә муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы **Галиева** Әминә Габделәхәт кызына; «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Совет районы администрациясе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы урынбасары **Хәмзина** Айсылу Ирек кызына; «Менделеевск муниципаль районындагы «Камские зори» балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют» дәүләт казна учреждениесе директоры **Миронов** Павел Степановичка **«Татарстан Республикасының атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Тест

САБЫЙДАН – ДАҺИГА

Апрель – бөек шагыйрь Габдулла Тукай ае. Туган көне җитәрәк, аның турында белемнәрегезне тикшерергә булдык.

1. Габдулла Тукайның туган елы кайсы?
А. 1882.
Б. 1886.
В. 1880.

2. Ничә яшеннән шигырьләр иҗат итә башлый?
А. 3.
Б. 10.
В. 16.

3. Аны кайсы рус шагыйрьләренең иҗаты кызыксындырган?
А. Уитмен, Пушкин.
Б. Достоевский, Байрон.
В. Пушкин, Лермонтов.

4. Кайсы шәһәрдә Тукай исемендәге урам юк?
А. Казан.
Б. Әнкара.
В. Мәскәү.

5. *«Мин торам кырларда,*
Болында, урманда
Уйныймын, очамын
Якты көн булганда».
Бу өзек кайсы шигырьдән?
А. «Кәҗә белән сарык».
Б. «Бала белән күбәләк».
В. «Шүрәле».

6. Казанда Тукай һәйкәленең (Пушкин урамындагысы) авторы кем?
А. Бакый Урманче.
Б. Харис Якупов.
В. Садри Ахунов, Лев Кербель, Лев Писаревский.

Җаваплар: 1) А; 2) В; 3) В; 4) В; 5) Б; 6) В.

АГИЛӘ КИТАЕВА:

«Кул эшләре белән мавыгуым кечкенә бер бизнеска әйләнде»

Балаларның нинди генә шөгыльләре, нинди генә сәләтләре юк хәзер. Шундый сәләтле балаларның берсе Агилә КИТАЕВА фоамираннан чәч каптыргычлары, төрле эшләнмәләр ясый. Матур-матур чәч бизәү әйберләре ясау серләрен ул безгә дә сөйләде.

:: Кул эшләре белән ничек мавыгып киттең?
– Өченче ел мин кул эшләре түгәрәгенә йөри башладым. Анда без фоамираннан чәч каптыргычлары ясый идек. Миңа бу шөгыль бик ошады. Ел ярым йөрдем, аннан бу матур эшләнмәләрне сата башларга уйладым. Башта заказлар аз иде, тик мин туктамадым. Әни реклама белән ярдәм итте һәм бизнес үсә башлады. Бер елдан соң даими сатып алучыларым да барлыкка килде.

:: Мондый эшләнмәләрне ясауның берәр сере бармы?
– Барысы да бик җайлы. Иң беренче кәгазьдә яки катыргыда каптыргыч өчен кирәкле детальләрне ясыйм һәм кисеп алам. Шаблоннарын интернетта да табып була. Гомумән, мондый эшләнмәләр буенча мастер-класслар күп анда. Теләгән һәр кеше өйрәнә ала. Детальләрне пастель буяулар белән әйләндереп алам, бизәкләрен ябыштырам. Иң соңгысы – бизәү һәм төрү эшләре.

:: Син ясаган чәч каптыргычлары арасында татар түбәтәе рәвешендәгеләре дә бар. Милли төсмерле эшләнмәләрне ясау идеясе ничек барлыкка килде?
– Мин социаль челтәрләрдә татар орнаментлы киемнәр, үзенчәлекле бизәнү әйберләре ясаучыларның аккаунтларын күзәтеп барырга яратам. Алардан илһамланып, үзем дә әлеге милли бизәкләр белән чәч бизәү әйберләре ясап карарга булдым. Узган җәй Сабантуйдагы ярминкәдә үземнең эшләнмәләремне тәкъдим иттем.

:: Кул эшләре белән киләчәктә дә шөгыльләнергә телисеңме?
– Кул эшләре минем өчен кечкенә бер бизнеска әйләнде, ә киләчәктә мин фотограф булырга телим. Миңа кешеләрне һәм табигатьне фотога төшерү бик ошый. Бик матур килеп тә чыга.

:: Тагын нинди кызыксынуларың бар?
– Быел мин гитарада уйный башладым. Безнең өй тирәсендә генә «Импульс» дигән яшүсмерләр клубы бар. Шунда йөрим. Гитарада уйнау бик ошый.

:: Буш вакытларыңда нәрсәләр белән шөгыльләнергә яратасың?
– Буш вакытларымда, гадәттә, мин гитарада уйныйм, төрле тәм-томнар әзерләргә яратам. Гаиләбез белән кичләрен өстәл уеннары уйныйбыз. Шулай ук, күп вакытымны дәресләргә багышлыйм, энеләремне карыйм. Сүз уңаеннан, алар минем бишәү!

:: Биш энегә апа булу ничегрәк ул? Авыр түгелме?
– Юк, авыр түгел, киресенчә алар белән бик күңелле. Бергә уйныйбыз, уку-язуга өйрәнәбез. Әмир һәм Самирны беренче сыйныфка мин әзерләдем, алар белән шөгыльләндем. «Бишле»ләргә генә укый алар хәзер.

Кунагыбыз турында белешмә

- ✓ Агиләгә – 11 яшь, ул өйдә торып укый.
- ✓ Әмир, Самир, Радмир, Таһир, Аммар исемле бертуганнары бар.
- ✓ Кул эшләре белән шөгыльләнә, гитарада уйный.
- ✓ Киләчәктә фотограф булырга тели.

:: Яраткан фильмың?
– «Гарри Поттер». Миңа фантастика бик ошый.

:: Илһам чыганагың?
– Табигать.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

Безгә язалар

Без – әти кызлары!

Әти хакы… Бу төшенчәне ничек аңларга? Әти хакын ничек хакларга?.. Аның өчен ниләр эшләргә кирәк? Уйларым белән шушы сорауларга җавап эзлим… Әлеге төшенчәнең асылын бик тә аңлыйсым килә. «Әни хакы», «күрше хакы» дигәнне күп тапкырлар ишеткәнем бар: әдәби әсәрләрдә дә, мәкаль-әйтемнәрдә дә бу хакта күп языла, әйтелә. Әни белән әти аерылгысыз бит, гаиләдә матур итеп яшәү, бәхетле бала булып үсү өчен, безгә бу хөрмәтле кешеләребез икесе дә бертөрле кирәк, бер дәрәҗәдә кадерле!

Фикерләремне әниемә рәхмәт сүзләре белән дәвам иттерәсем килә. Ни өчен әниемә, диярсез? Аңлатырга тырышып карыйм. Безнең гаиләдә әтиебез – бик кадерле кеше. Юк, әнием, ике апаем һәм минем арада бердәнбер ир кеше булган өчен генә түгел. Әтиебезгә хөрмәтне бездә нәкъ менә әнием уятты, дисәм дә ялган булмас. Әниемнең: «Әтиегездән сорагыз!» – дигән сүзләренең асылын без еллар узгач кына аңлый башладык. Нинди зирәк безнең әниебез! «Әтиегез кебек акыллы, хатын-кыз кадерен белә торган, эшчән егетләрне карагыз инде, балалар», – дип, әтиебез үрнәгендә безгә чын ир-ат образы тудырды. Чын ир-егетнең әтиебез кебек булырга тиеш икәнлеген без кечкенәдән белеп, аңлап үстек. Әниебез, шулай итеп, безгә сиздермичә генә, үзе генә белгән алымнар, юллар белән әтиебезгә хөрмәт тәрбияләгән икән бит!

Безнең гаиләдә соңгы сүзне әти әйтә, әтиебез эштән кайтмыйча ашарга утырмыйбыз, ул безне әле дә кочаклап-үбеп кенә тора; хәтта инде кияүгә чыккан апаем да, безгә кайткач, аның кочагыннан чыкмый. Без серләребезне дә иң беренче әтиебезгә сөйлибез. Бу да – әнием тәрбиясе, дип уйлыйм мин. Без әле төс-кыяфәтебез белән дә аңа охшаганбыз, безне «Раил кызлары» дип йөртәләр.

Әтиебез безнең бөтен башлангычыбызны күтәреп ала, аны тормышка ашырырга ярдәм итә. Апаемның профессиональ фотограф булып китүендә дә әтиемнең роле әйтеп бетергесез. Алтын куллы, тәртипле, төгәл, гаять белемле, әниебезне, туганнарын, дәү әнине бөтен җаны-тәне белән яратып, кайгыртып яшәүче кадерле кешебез – безгә зур үрнәк. Шундый әтинең кызлары булу – үзе зур бәхет бит! Әти хакын хаклый башлауның беренче адымы – әти кадерен, аның безнең өчен җан атып яшәвен, бөтенесен дә эшләвен аңлаудыр. Шуны аңлаудан әти хакын хаклау башлана да инде.

Күрше хакы – тәңре хакы,
Ата хакы аннан киммени?
Әтиләрне шундый олылыйбыз,
Тәңребезгә хәтта тиңлибез.

Гүзәл ВӘЛИЕВА,
Арча районы Иске Чүриле урта гомуми белем мәктәбенең
7 нче сыйныф укучысы

Укучылар иҗаты

Тукай абый

Бөек шагыйрь, дигәч, уйга
Килә бит безнең Тукай!
Аны белмәгән татарлар
Дөньяда да юк бугай.

Һәр бала таныша аның
Матур иҗаты белән.
Әкиятләрнең иң шәпләрен
Ул язган диеп беләм.

«Су анасы» һәм «Шүрәле»
Күңелдә урын алган.
Шул сихри әкиятләрдә
Матур балачак калган.

Бик күп аның шигырьләре
Матур әкиятләре…
Күпләргә бик таныш булган
«Бишек җыры» бар әле…

Габдулла Тукай исеме
Ул бит – йөрәк түрендә.
Тукайны укып үскәннәр
Әллә кайдан күренә.

Һәр кеше белеп сакласын
Иҗатын бу шагыйрьнең.
Белми калып, тик заяга
Уздырмасын гомерен.

Язилә СӘГЪДИЕВА.
Казан шәһәре

ТӨНГЕ ӘКИЯТ

Авылда бабам васыять итеп калдырган йорт бар. Ул бик зур да, артык кечкенә дә түгел. Янәшә торган өйләрдән дә бер җире белән аерылмый, тик аны бакча ягыннан зират коча. Ни дисәң дә, туып-үскән җир – туып-үскән җир инде. Ул барыбер үзенә тарта… Бабам мине нигез хуҗасы итеп сайлаган икән, аның өметләре акланырга тиеш. Менә шундый уйлар белән, гаиләмне алып, шәһәрдән авылга күчеп кайттым.

Авылның бер төне. Тәрәзәмнән трактор тәгәрмәче кадәр кып-кызыл ай карап тора. Йолдызлар да, күзәткәнне белгән шикелле, күз кысыша. Аһ, нинди рәхәтлек!.. Шушы матурлыкка хозурланып утырганда, уйларымны бүлдереп, тәрәзә шакыдылар. Нәрсә булды икән? Аянычлы хәбәр алып килделәрме әллә?

Шундый уйлар белән сәкемнән тордым һәм, үз эчемнән сөйләнә-сөйләнә, ишек янына бардым. «Кем бар анда?» – дип эндәштем. Минем соравыма җавап кайтаручы булмады. Урамга чыктым. Бер җан иясе дә юк. Тәрәзәмне кем шакыды икән? Өй тирәли әйләнеп килдем. Баксам, бакча ягына карап торган тәрәзә каршында җил малае миләш агачының тәлгәшләре белән уйный. Ул өй почмагына посып тора да, мин читкә борылуга, миләш тәлгәшләре белән тәрәзәмә кагыла.

Чү, монысы ни булыр?! Кемдер якынлашкан кебек, артымда мыш-мыш итеп сулыш та ала. Җитмәсә, борыны да сызгыра. Йа Раббым, ни булса да, берүк, саклый күр, Сиңа гына сыенам…

Шулай үз-үзем белән сөйләшеп йөргәндә, карлыккан тавыш чыгарып, ишек ачылды. Ишек ачылды да, тып-тып басып, өй эченә кемдер кереп китте. Әкрен генә борылдым, тирә-якны күзәттем. Ә аннары өйгә таба юнәлдем. Бервакыт агач башына күзем төште, анда, каргаларны куркытып, нидер үрмәли. Күзләре елык-елык килеп тора. Ул кинәт туктап калды да «чияк» дигән аваз салды һәм өзлексез чыркылдый башлады. Аның бу шомлы тавышы сабый елаган кебек тоела. Күршем Әхмәт абый әйткән иде: «Авылга Чияк ябалак килгән!» – дип. Ябалак икәнен аңласам да, мин тиз генә өйгә элдердем. Өемә керим дигәндә, борын төбемдә ишек шап итте дә ябылды. Бу йорт эченә үткән җан иясенең эшедер инде. Мин, калтырана-калтырана, ишекне ачтым, түргә уздым. Ә анда кемдер йөри, шәүләсе – сабыйныкы. Ул җан иясе сабыемның уенчыклары белән уйный, нидер кыра, җимерә. Мин озак итеп күзәтеп торганнан соң, ул кисәк борылды да:

– Әтием, минем йоклыйсым килми! – диде.

Мин, тынычланып, елмаеп:

– Кызым, йокла инде, иртәгә тора алмассың! – дидем.

Бүлмәсенә алып кердем, Габдулла Тукайның «Ай һәм кояш», «Ак бабай», «Сөткә төшкән тычкан» әсәрләрен сөйләп, аны йоклаттым. Сабыемның нәни куллары белән сыйпавына үзем дә йокымсырап киткәнмен. Өй эченә тынлык урнашты, ә урамда җил малае яңгыр кызы белән үзләренең мәхәббәт җырын көйләде. Бары тик яшен агай гына, болытлар арасыннан бертуктаусыз утлы йодрыгын айкап, кемнедер сүкте.

Яшенле яңгыр тавышына оеп утырганда, чормада нидер дөбердәп куйды. Дөбердәп куйды да йокыны качырды. Ут сүнде. Бүлмәгә караңгылык хуҗа булды. Башыма шомлы уйлар керә башлады. Шул арада, сискәндереп, түр ягымда тагын нидер дөбердәп куйды. Монысы ни булыр? Бүлмә ишекләре котны алырлык тавыш белән җанымны өркетеп җырлый башлады. Аларны җырлатучы дирижер да, кырт-кырт басып, мин утырган бүлмәгә якынлашты. Яшен яктысында шыксыз сурәте дә күренгәләп алды. Аның тузгыган чәчләре, өстенә кигән озын ап-ак күлмәге Әхмәт абый сөйләгән бичураны хәтерләтте. Менә без аның белән күзгә-күз карашып торабыз. Бу минутларда вакыт тукталгандай булды. Аның сулыш алганы якынайганнан-якынайды һәм ул кулларын миңа сузды. Куркуымнан мин күзләремне чытырдатып йомдым. Күзләремне йомгач, бу шомлы караңгылыкны яктырткандай: «Матурым, мин кайттым, урамда коеп яңгыр ява, куркам!» – дигән нәфис тавыш ишетелде. Күзләремне ачсам, янымда – сөйгәнем; үзе дер-дер калтырый, чыланып беткән. Аның эштән кайтуына ут бетү сәбәп икән.

Озак та үтмәде, кемдер ишекне усал итеп дөбердәтте. Монысы инде кем булыр? Ишек шакучы тагын каты итеп дөбердәтте. Куркуымны җиңеп, ишек янына бардым. Ишек дөбердәтүченең рәвешен күреп, тагын котым алынды. Өстендә озын плащ, башына капюшон кигән, кулында чалгы. Күзләре яшен яктысында янып тора, ә чалгысы елык-елык ялтырый. Мин уйлап куйдым: «Бу – үлем фәрештәседер инде». Уйланып торганда, ул миңа дәште: «Аюбәкер, Аюбәкер, ни булды?» Шул арада ут янды. Карасам, күршем Әхмәт абый кергән. Ул миңа карап-карап торды да тагын эндәште: «Аюбәкер, яңгыр яугач, печәнгә барып булмас, чалгыңны керттем!» Мин тынычланып калдым, тау артыннан, дөньяны яктыртып, кояш чыккандай булды, яңгыр болытлары таралгандай, өркүем юкка чыкты.

Күрше Әхмәт абый, минем кыяфәтне күреп, гаҗәпләнеп, тагын сорады: «Аюбәкер, ни булды?»

Мин:

– Әй, Әхмәт абый, нигәдер шүрләп куйдым, бүгенге хәлләр элек син сөйләгән бер әкияткә охшаган! – дидем.

Ул:

– Әй, энем, яшь чагында сөйләгән әкиятләремә әле дә ышанып яшәсәң, морҗаңнан төтен чыкмас! – дип көлеп җибәрде.

Алмаз ӘХМӘТГАЛИЕВ

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7066 данә
Гомуми тираж – 16091 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 258

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+